РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«24» май 2024 ел г. Альметьевск № 1881

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Капиталь төзелеш объектларын төзүгә рөхсәт бирү тәртибен, объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирү, планлаштырылган төзелеш турында хәбәр итү һәм төзелгән индивидуаль торак төзелеше объектларына яисә бакча йортына туры килү тәртибен раслау турында» 2021 елның 16 апрелендәге 552 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 25 декабрендәге 627-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Капиталь төзелеш объектларын төзүгә рөхсәт бирү тәртибен, объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирү, планлаштырылган төзелеш турында хәбәр итү һәм төзелгән индивидуаль торак төзелеше объектларына яисә бакча йортына туры килү тәртибен раслау хакында» 2021 елның 16 апрелендәге 552 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 27 мартындагы 684 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1 нче кушымтада карарга:

2.5.1 пунктындагы егерменче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү территория чикләрендә башкарылырга планлаштырылган очракта территорияне комплекслы үстерү турында килешүнең күчермәсе, территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән, ә территорияне комплекслы үстерү турындагы карарны гамәлгә ашыру килешү төзелмичә башкарыла икән, территорияне комплекслы үстерү турындагы карарның күчермәсе. Шул ук вакытта комплекслы үсешкә дучар булган территория чикләрендә капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү очрагында, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджеты акчаларын җәлеп итеп, территорияне комплекслы үстерү турында мондый килешүнең күчермәләрен бирү һәм (яки) карар таләп

ителми.»;

б) 3.2 бүлегенең 3.2 пунктындагы тугызынчы абзацында «экологик күзәтчелекне» сүзләрен «экологик контрольне (күзәтчелекне)» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар, 2024 елның 1 сентябреннән үз көченә керә торган карарның 1 пунктындагы б) пунктчасыннан тыш, рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары И.И. Сәлимгәрәевка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Каюмов